Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районының
Клементейкино авылы башкарма комитеты

КАРАР

14 январь 2026 ел №1

Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авылы башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 06 апрелендәге 6 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 31 июлендәге 304-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә

Клементейкино авылы башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Клементейкино авылы башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 06 апрелендәге 6 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районының Клементейкино авылы башкарма комитетының 2022 елның 25 июлендәге 11 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктындагы 4 пунктчасында «мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен эшкәртү кирәк» сүзләрен «мөрәҗәгать итүче тарафыннан мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси күрсәткечләрен бирү һәм аларны эшкәртү кирәк» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 2.5 бүлегенең 2.5.1 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Мөрәҗәгать итүче булмаган затның шәхси белешмәләре җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча вәкаләтләрен үтәү өчен ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы ярдәмендә бирелгән очракта, мөрәҗәгать итүчегә мондый белешмәләр күрсәтелмичә, мондый затның яисә аның законлы вәкиленең күрсәтелгән максатларда мондый затның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалыгын алу таләп ителми.»;

1.3. 2.8 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.8.5 пункт өстәргә:

«2.8.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарткан очракта, күрсәтелгән хезмәтләрне күрсәтүче органнар, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук дәүләт яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартуга китергән федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән таләпләр исемлеген күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында хәбәр итәләр.»;

1.4. 2.10 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге.».

2. Әлеге карарны торак пункт территориясендә Әлмәт районы, Клементейкино авылы, Центральная урамы, 38А йорт; Багряж авылы, Кызыл Йолдыз урамы, 38А йорт; Яңа Чишмә авылы, Гафиятуллин урамы, 3А йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә; «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Клементейкино авылы
башкарма комитеты җитәкчесе Л.Э. Языков